КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 май г.Казань № 366

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» гранты турында» 2010 ел, 21 май, 398 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» гранты турында» 2010 ел, 21 май, 398 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 23 февраль, 157 нче; 2013 ел, 11 май, 319 нчы; 2013 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 25 сентябрь, 673 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1019 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 400 нче; 2016 ел, 28 октябрь, 795 нче; 2016 ел, 28 декабрь, 1019 нчы; 2017 ел, 14 июнь, 387 нче; 2018 ел, 29 март, 184 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» гранты турындагы нигезләмәне бу карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантын бирү буенча

республика комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 11 нче пункт өстәргә:

«11. Грант алуга конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, грант алуга конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү процедурасын бозулар булганда, грантка дәгъва итүче Республика комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция грант алуга конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре игълан ителгәннән соң календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә, ирекле рәвештә язылып, алга таба Республика комиссиясе тарафыннан карап тикшерү өчен Министрлыкка кертелә.

Республика комиссиясе апелляция бирү вакыты тәмамланган көннән җиде эш көне эчендә апелляцияне карап тикшерә. Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар Республика комиссиясе тарафыннан, ачык тавыш биреп, Республика комиссиясе утырышында катнашучылар санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булган очракта, Республика комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була. Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Республика комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклау турында;

апелляцияне канәгатьләндерү турында.

Карар тиешле ярдәмче комиссиясенең рәисе һәм утырышта катнашучы Республика әгъзалары имза куя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.»;

әлеге карар белән расланган Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантын бирү буенча республика комиссиясе составын бу карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин